**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 4 март № 132

г. Казань

«Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының эшләп торучы «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – бюджет учреждениесе) тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен (алга таба – казна учреждениесе) оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

казна учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы башкара дип;

казна учреждениесе эшчәнлегенең максаты булып Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру өлкәсендәге дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру тора дип;

казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат саны 27 штат берәмлеге тәшкил итә дип.

3. Татарстан Республиканың Икътисад министрлыгына:

бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең штат саны кыскару процессында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә;

ике ай эчендә бюджет учреждениесе уставындагы тиешле үзгәрешләрне расларга.

4. Казна учреждениесе эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү «2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законы белән «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы» ведомствосы, 04 бүлек, «Милли икътисад өлкәсендәге башка мәсьәләләр» дигән 12 бүлекчә буенча күздә тотылган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\132.doc